КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 июнь г.Казань № 755

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турында» 2016 ел, 17 август, 569 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турында» 2016 ел, 17 август, 569 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 25 гыйнвар, 37 нче; 2019 ел, 17 сентябрь, 841 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1192 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2025» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия комиссиясе составында:

комиссия составыннан Р.Р.Кыямовны, А.А.Кондратьеваны, Т.Д.Сөләйманoccовны, Г.Р.Шакированы чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, комиссия рәистәше Ринат Наил улы Садыйковны;

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары, комиссия рәисе урынбасарсы Айгөл Азат кызы Сабированы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Раушан Булат улы Зариповны;

«Татарстан Республикасы Студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президенты Шамил Наил улы Якуповны (килешү буенча);

Наталья Дмитриевна Пивоварованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының гражданлык патриотизмы бүлеге башлыгы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин